Бүгенге санда:



Коррупцион факторларга юл куелмый. 2 бит


# Дуслык

Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе 8 июль 2015 ел

№ 49 (10578)


**9 июльгә һава торышы:** болытлы һава, җил төньяк-көнбатыштан 2-3 м/с; температура көндез +23°С, төнлә +18°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

## МӨМКИНЛЕКЛӘР КИҢӘЯ

Бу көннәрдә Нурлат аграр техникумында кызу чор – документлар кабул итү бара. Быел техникумда яңа – икътисад һәм бухгалтерлык исәбе, пешекче-кондитер белгечлекләре буенча да төркемнәр туплыйлар.

## ИНГЛИЗЧӘ БЕЛҮ ФАЙДАСЫ

Шәһәрнең 2нче һәм 3нче урта мәктәпләре укучылары Дамир Мөхәммәтҗанов белән Данияр Гатин "Костер" республика балалар сәламәтләндерү-мәгариф үзәгендә узачак XI инглиз-лингвистик профиль сменасында ял итәчәк. Смена 11-28 июльдә уза. Анда укучылар инглиз телендә әңгәмәне уңышлы үтеп узганнар.

## КОМИССИЯ ШТРАФ САЛГАН

Балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиянең сишәмбе көнне узган утырышында 36 материал каралган. Комиссия секретаре Гүзәл Ганиева әйтүенчә, районда җәйге чорда эчүче, балаларын тәрбияләмәүче ата-аналар саны арткан. Моннан тыш, төнге 11дән соң урамда йөрүче 5 яшүсмернең әти-әнисенә 500әр сум штраф салынган.

## ГАИЛӘ КӨНЕНӘ БАГЫШЛАП

9 июль көнне 18.00 сәгатьтә Халыклар дуслыгы йортында Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көненә багышлап зур бәйрәм үткәрелә. Бәйрәмгә рәхим итегез!

## КАБУЛ ИТҮ ҮТКӘРЕЛӘ

14 июль көнне иртәнге 10да шәһәр Мәдәният сараенда ТРда бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм республика Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча күчмә кабул итү үткәрәләр. Кабул итүгә алдан язылу өчен тел.: **2-91-11.**

# Газета фатихасын алган гаилә




ӘБДЕЛГАЛИЕВЛАРГА "ДУСЛЫК" ФАТИХА БИРДЕ

**Бүген илебездә – Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне. Бу бәйрәм 2008 елдан бирле билгеләп үтелә һәм ул шул көннең символы булган ромашка кебек популярлык казанырга өлгерде инде. Ромашка гаилә назын һәм бәхетен чагылдыра.**

Бу көн Рәфис һәм Эльза Әбделгалиевлар гаиләсе өчен дә истәлекле. Алар дүрт ел элек, 9 июльдә, газетабыз 80 яшьлек юбилеен билгеләгән көндә гаилә корганнар. Ул чакта "Дуслык" яшь гаиләне кунакка да чакырган иде, һәм туй кортежы редакциягә дә сугылып чыкты. Баш мөхәррир Сәкинә Хәйруллина, аларга бүләк тапшырып, фатихаларын да җиткерде. Әйтергә кирәк, "Дуслык"ның җылы теләкләре тормышка ашты.

Рәфис һәм Эльза җылы гаилә корганнар, хәзер алар ике бала – Рияз белән Гөлназны үстерәләр.

– "Дуслык"ның фатихасы гаять уңышлы булды. Нәкъ шул көннәрдә без булачак йортыбызга нигез салдык, – дип сөйли гаилә башлыгы Рәфис.

Эльзаның кулында ромашкалар, аларның йөзендә ягымлы елмаю чагыла, гомумән, Әбделгалиевлар бергәләшеп хыялларын тормышка ашырачакларына ышанып яшиләр. Димәк, алар "Дуслык"ның мәхәббәт һәм тугрылыкны, гаиләне ышанычлы итеп сакларга дигән үгет-нәсыйхәтләрен дә үтәп яши. Моңа редакция коллективы да бик шат. Ә иртәгә газета үзенең 84 яшьлеген билгеләп үтәчәк. Шул чорда газетаның якын дуслары күпләп пәйда булды, яшь Әбделгалиевлар гаиләсе кебек үк, тугры юлдашларыбыз, традицияләребез дә бар. Газета исә дусларыннан котлаулар кабул итә һәм киңәшләре белән дә юмарт уртаклаша. "Дуслык"ка Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне кебек бүгенге бәйрәмнең асылы аерата якын. Гаилә бәхетенең мәңгелек кыйммәтләре, ярату, тугрылык, бер-береңне аңлау һәр Нурлат гаиләсенең гомерлек юлдашы булсын иде.

Валентина **ВАФИНА**

АКТУАЛЬ

# Балалар йөртүнең үз кагыйдәләре бар

**Балаларны шәһәрара сәяхәтләргә районда Нурлат АТПсы, район башкарма комитетының мәгариф бүлеге, "Ледок", Галимҗан Хөсәенов исемендәге балалар-үсмерләр спорт мәктәпләре транспорт чаралары гына йөртә алачак.**

1 июльдән балалар йөртүче автобусларга яңа таләпләр кертелде. Транспорт чарасының яше 10 елдан артмаска тиеш һәм аның тахограф, шулай ук "ГЛОНАСС +112" спутник навигациясе аппаратурасы, иминлек каешлары, видеорегистратор, "Перевозка детей" дигән билгеләр белән җиһазландырылуы мәҗбүри. Моннан тыш, балалар автобусларда бары өлкәннәр озатуында һәм югары квалификацияле шоферлар белән генә йөртелергә тиеш. Бу хакта районның юл хәрәкәте иминлеге комиссиясенең узган атнада үткән утырышында әйтелде. Балаларның юллардагы иминлеге – һәрвакыт актуаль мәсьәлә. Уку елы дәвамында гына да районда 3 меңнән артык бала өчен төрле заказлы ташу оештырыла.

– Сер түгел, моңа кадәр балалар автобусларда кагыйдә бозулар белән йөртелә иде, – диде ЮХИДИ бүлеге начальнигы Рөстәм Гарипов. – Аның бөтен илне тетрәндерерлек аянычлы нәтиҗәләре дә булды. Бездә дә каникуллар башыннан гына да район юлларында балалар катнашында 3 юл-транспорт һәлакәте теркәлде. Шөкер, балалар исән, һәм аварияләр дә автобуслар катнашында түгел. Автобусларның "ГЛОНАСС +112" системасы белән җиһазлануы транспорт чарасының хәрәкәт маршрутын һәм тизлеген контрольдә тотарга ярдәм итә. Монда республика Хөкүмәт программасының роле зур булуын билгеләп үтәргә кирәк.

ЮХИДИ бүлегендә әйтүләренчә, яңа кагыйдәләрне үтәү өчен документлар исемлеге бар. Алар машина йөртүчеләргә һәм сәяхәтне оештыручыларга да кагыла. Оештыручылар яшь пассажирларның шәһәрара сәяхәте турында өч көн алдан ЮХИДИ бүлегенә хәбәр итәргә тиеш. Шул вакыт эчендә транспорт чарасының техник торышы тикшерелә, машина йөртүче рейс алды инструктажы, медицина тикшерүе уза. Моннан тыш, "Д" категориясенә ия булган шоферның стажы 3 елдан да ким булмау шарт. Яңа таләпләр нигезендә, яшь пассажирларны автобуста медицина хезмәткәре белән педагог озата барырга тиеш, азык-төлек, маршрутның программасы, графигы булу зарур.

Юл хәрәкәте иминлеге район комиссиясе рәисе, район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин сүзләреннән аңлашылганча, районда балаларны ташу буенча бары махсус матди-техник базасы булган оешма гына шөгыльләнергә һәм ул алда телгә алынган барлык кирәкле компетенцияләрне үз эченә алырга тиеш.

Зилия **ӘКСАНОВА**

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

ҖӘҺӘТ ӘҢГӘМӘ

## Әсхәт Габдуллин: “Отышлы сатып алулар коррупциядән саклый”

**Муниципаль тармакта инде ел ярымлап товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу контракт системасы буенча үткәрелә.**

Бүгенге көндә нинди нәтиҗәләр турында сөйләргә була – без моның белән Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе **Әсхәт Габдуллиннан** кызыксындык.

**– Әсхәт Касыймович, нурлатлылар сатып алулар өлкәсендә контракт системасына кушылганда, нинди максатлар куелган иде?**

– Иң элек, бу күчеш мәгълүмати ачыклык, намуслы конкуренция, бюджет средстволарын максатчан һәм икътисади яктан нәтиҗәле файдалану принципларын кертүгә бәйле. Төп момент буларак сатып алулар өлкәсендә коррупцион факторларны бетерү, шулай ук заказчыны отышлы шартларда сыйфатлы продукция белән үзвакытында тәэмин итү дә күздә тотылды. Кабатлап әйтәм, отышлы шартларда, нәкъ менә шуның хисабына икътисади һәм антикоррупцион нәтиҗәгә ирешелә дә инде. Бүген без боларны уңышлы гына гамәлгә ашырып киләбез, дип әйтергә мөмкин.Районда 1нче яртыеллыкта сатып алу процедураларының икътисади нәтиҗәлелеге 7,6 процент тәшкил иткән. Ел ярым эчендә барлык катнашучылар да муниципаль сатып алуларга конструктив кушылдылар. Барлык этаплар да максималь аерымачык.

**– Шуңа да карамастан, сатып алуларны гамәлгә ашыру турында сөйләгәндә, һәрчакта да диярлек сүз коррупция турында бара. Сатып алулар коррупциясез генә була аламы?**

– Сатып алуларны гамәлгә ашыру, поставщикны билгеләү – болар үзеннән-үзе зур рисклы эшчәнлек. Чөнки нәтиҗәлелек һәм коррупция рискы үзара тыгыз бәйләнештә бит. Кайчагында аларны аеру һәм бетерү бер-берләренә нәкъ капма-каршы ысуллар белән ирешелә. Шуңа да сатып алу эшчәнлегендә нинди коррупцион рисклар булуын белеп тору мөһим.

Мисал өчен, сәүдәләрдән алынган зур экономия турында сүз барганда, иң беренче чиратта, сатып алуның бюджеты дөрес исәпләнелгәнлеге турында әйтергә мөмкин, ул арттырылган саен коррупцион риск та зуррак була.


Автор фотосы

**– Коррупция нинди ысуллар белән юкка чыгарыла?**

– Мисал белән аңлатам. Базар тикшерелә. Биредә нечкәлекләр бик күп. Андыйларга иң элек, мөмкин булган поставщикларның яки продукциянең нигезсез киңәйтелүе һәм чикләнелүе керә. Контракт шартларына һәм аның башкарылуына кагылышлы хаталар җәһәтеннән дә шул сәбәпләрне әйтергә мөмкин. Поставщикны билгеләүне нигезсез катлауландыру яки гадиләштерү ихтималы да бар. Моннан тыш, гамәлдәге законнарда поставщикны билгеләү ысулын сайлаганда, коррупцион рисклар азаккача исәпкә алынмаган. Гомумән, бу – сатып алуның һәр этабында үздырылучы зур чаралар комплексы. Әңгәмәбезгә нәтиҗә ясап, сатып алуларны коррупциясез башкарырга мөмкин, дип билгеләп үтәсем килә. Моның өчен сатып алу циклының барлык стадияләрендә дә коррупцион рискларны грамоталы итеп читләтеп узарга һәм аларның барлыкка килү шартларын юк итәргә кирәк. Боларның барысын да законнар яссылыгында да, заказчы куя торган таләп-шартларда да исәпкә алу зарур. 44нче Федераль закон нигезендә, безнең барлык сатып алуларыбыз да җәмәгатьчелек өчен аерымачыкка һәм җәмәгать контроленә кулайга әверелде, тулаем сатып алу циклы өчен законнар җыелмасы гамәлдә, заказчының, поставщик һәм контроль алып баручы органның хокуклары һәм җаваплылыгының тигезлеге тәэмин ителгән. Яхшы нәтиҗәләргә ирешү өчен без үз эшебездә профессионаллар сүзенә колак салуны хуп күрәбез, күпчелек очракта мактауга түгел, ә тәнкыйтькә игътибар бирәбез. Башкарасы эшләребез бар әле, дип саныйм, андыйлардан сатып алу эшчәнлегендә катнашучыларны профессиональ әзерләүне дә, зур рискларны иминиятләштерүне дә әйтергә мөмкин. Моннан тыш, процесста катнашуга бары тик квалификацияле, тәҗрибәле һәм чиста репутацияле тәртипле гражданнарның гына кертелүе дә мөһим.

**– Әңгәмәгез өчен рәхмәт.**

Валентина **ВАФИНА**

### ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

## ПАРТИЯДӘН КАНДИДАТ

**Узган шимбәдә “Бердәм Россия” партиясе Татарстан төбәк бүлекчәсе XXIII конференциясенең I этабында Нурлаттан җирле бүлекчә секретаре Равил Кузюров җитәкчелегендәге делегация катнашты.**

Аның составында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Шамил Яһудин, район Советы аппараты җитәкчесе Олег Микушкин, җирле бүлекчә башкарма комитеты җитәкчесе Ралия Ханиева, башлангыч бүлекчәләр секретарьлары Рамилә Әхмәтшина, Владимир Гаврилов һәм Владимир Михейкин бар иделәр. Конференциядә делегатлар күпчелек тавыш белән партиядән Президентлыкка кандидат итеп республика лидеры Рөстәм Миннехановны тәкъдим иттеләр.

– Рөстәм Миннеханов кандидатурасы өчен 316 делегатның 313есе тавыш бирде. Бу республика җитәкчесенә булган ышаныч турында сөйли, – дип тәэсирләрен уртаклашты Тимерлек башлангыч бүлекчәсе секретаре Владимир Гаврилов. – Рөстәм Нургалиевичның конференциядәге чыгышы да тәэсирле булды. Республика башлыгы быелгы программаларны вакытыннан алда үтәп, инде 2016нчы елга бурычлар билгеләүне максат итеп куйды. Партия сайлаучылар белән бергә булырга, иң беренче чиратта аларны борчыган сорауларны хәл итәргә тиеш, дип ассызыклады. Моның өчен республикада дистәләгән программа тормышка ашырыла инде. Республикада “Стратегия – 2030” программасы кабул ителде, ул да Татарстанның социаль-икътисади үсешендә мөһим этап булачак. Һәм бу эшләр, һичшиксез, Татарстанның бүгенге лидеры Рөстәм Миннехановның зирәк җитәкчелеге белән башкарылырга тиеш дип саныйм, һәм шуңа барыбыз да аның кандидатурасы өчен тавыш бирдек тә.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

### БЕЛДЕРҮЛӘР

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашуга хокукларының төп гарантияләре турында” ФЗның 50нче, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 60нчы маддәләре нигезендә, “Дуслык” (“Дружба”, “Туслах”) газетасы редакциясе Татарстан Республикасы Президенты сайлаулары буенча теркәлгән кандидатларга, шулай ук “Нурлат муниципаль районы” һәм “Нурлат шәһәре” муниципаль берәмлекләре вәкиллекле органнары депутатларын сайлаулар буенча теркәлгән партияләр һәм кандидатларга 2015 елның 15 августыннан 12 сентябренә кадәр(00:00) сайлау алды агитациясе урнаштыру өчен түләүсез һәм түләүле басма мәйдан бирү турында хәбәр итә.

1. Түләүсез басма мәйданның күләме бер атнага:

– җомга көнне А3 форматының 1,2 полосасын (беренче полосадан тыш) тәшкил итәчәк.

2. Түләүле басма мәйданның күләме бер атнага:

– чәршәмбе көнне А3 форматының 1,2 полосасын (беренче полосадан тыш) тәшкил итәчәк.

Түләүле басма мәйданның бәясе кв.см өчен 48 сум тәшкил итәчәк.

3. Түләүле һәм түләүсез басма мәйданны бүлү буенча жирәбә һәм сайлау алды агитациясе урнаштыруга килешүләр төзү редакция бинасында (Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19) 10 августта 10.00 сәгатьтә үткәреләчәк.

***

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукларының төп гарантияләре турында”гы ФЗның 50нче, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 60нчы маддәләре нигезендә, “Дуслык” (“Дружба”, “Туслах”) газетасы редакциясе Татарстан Республикасы Президенты сайлаулары буенча теркәлгән кандидатларга, шулай ук “Нурлат муниципаль районы” һәм “Нурлат шәһәре” муниципаль берәмлекләре вәкиллекле органнарына сайлаулар буенча теркәлгән партияләр һәм кандидатларга 2015 елның 15 августыннан 12 сентябренә кадәр (00:00) nurlat-tat.ru сайтында сайлау алды агитациясе урнаштыру өчен түләүле публикацияләр бирү мөмкинлеге турында хәбәр итә.

1. nurlat-tat.ru сайтында бер график элемент белән бер түләүле материалның бәясен 1200 сум, ике яки аннан да күбрәк график элемент, өстәмә бизәү белән – 1500 сум дип билгеләргә.

2. Сайтта түләүле язмаларны бүлү буенча җирәбә һәм сайлау алды агитациясе урнаштыруга килешүләр төзү редакция бинасында (Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19) 10 августта 10.00 сәгатьтә үткәреләчәк.

ПРИЗ СЕКТОРЫ

## РЕДАКЦИЯГӘ ЧАКЫРАБЫЗ

**Редакциядә әбунә акциясе нәтиҗәләре буенча җәйге призлар уйнату үтте.**

1. Җилләткеч – Нурлат, Үзәк ур., Г.Я.Калентьева.
2. Миксер – Зирекле, Салих Сафиуллин.
3. Чәй сервизы – Чуваш Мәнҗесе, Шоссе ур., Наталья Кириллова.
4. Чәч алу машинкасы – Биляр Озеро, И.Н.Кайзер.
5. Плед – Якты Күл, Рәйсә Фәйзуллина.
6. Электр чәйнеге – Нурлат, Асарова (альтернатив әбунәче)
7. Су өчен фильтр – Абрыскино, Виталий Егоров.
8. Картина – Урта Камышлы, Иван Гаврилов.
9. Мендәр – Илюткино, Николай Казаков.
10. Чәч кистерү өчен купон – Нурлат, Ленинград ур., 24, Фәхретдинова.
11. Кухня сөлгеләре җыелмасы – Ерепкино, А.А. Соловьев.
12. Юрган – Нурлат, Тукай ур., 28, О.В.Билданова.
13. Пиццериягә купон – Нурлат, Гыйматдинов ур., 132, Лилия Гыйльметдинова.
14. Түгәрәк тартмада чәй сервизы – Нурлат, Нефтьчеләр ур., 24,Хлебушкиннар.
15. “Дуслык”тан котлауга купон – Яңа Әлмәт, Вәсилә Нәбиуллина.
16. “Нурлат” ТРКсыннан котлауга купон – Егоркино, Үзәк ур., 42, Елена Михеева.
17. Сәламәтлек клубына купоннар – Нурлат: Синдряков ур., 39, ..., Шәяхмәтова; Җиңү ур., 6, Волкова; Козлов ур., 14, .., Гыйльманова; Сәлимҗанов ур., 11,.., Г.Г.Сөләйманова; Карл Маркс ур., 23,.., Д.М.Халитова; Гыйматдинов ур., 97, А.В.Захарова; Кариев ур., 6, .., М.В.Хәмитова.
18. Плед- Нурлат, С. Ханипова (альтернатив әбунәче)
19. Фен – Түбән Нурлат, Фәрит Гафуров.

**Приз отучыларны паспорт һәм квитанцияләре белән пәнҗешәмбе көнне 9.30да көтәбез.**

# КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Хөрмәтле дустыбыз **Ралия Габдулловна Хәсәншинаны** ихлас күңелдән юбилее белән котлыйбыз!

Гомерегезнең алтын чорын гаиләгез, туганнарыгыз, хезмәттәшләрегез һәм дусларыгыз арасында кадерле кеше булып каршы аласыз. Игелекле, юмарт, киң күңелле булып, хезмәт сөеп яши белүегезгә язмыш бүләге бу! Чын күңелдән бәхетегезнең гомерлек булуын телибез! Тормыш юлыннан гел яшь күңелле булып, безнең ихтирамыбызны, якыннарыгызның яратуын тоеп атларга язсын! Сезгә бәхетле булу бик тә килешә!

**Дусларыгыз Флюра Рәшитовна, Дилүсә Кадыйровна, Резеда Әкрамовна, Сәкинә Нурулловна.**

## НЕДВИЖИМОСТЬ

*дом, варианты. Т. 8-919-684-40-03.

*1-комнатная квартира, сах.завод, 800000 руб., торг. Т. 8-927-401-25-35.

*2-комнатная квартира, 1 этаж, аэропорт. Т. 8-927-245-42-85.

*дом с земельным участком, подведены газ, свет, в селе Вишневая Поляна. Т. 8-937-283-73-19.

*дом, квартира. Т. 8-927-041-39-93.

*комната в г.Самара, рядом с мед. университетом. Т. 8-927-032-23-03.

*дом, ж/д. Т. 8-927-676-25-75.

*3-комнатная квартира, гараж, ул. Нефтяников. Т. 8-937-003-95-54.

*1-2 коттеджа с. Шламка, с надворными постройками. Т. 8-927-760-74-87.

*дом г. Нурлат: газ, вода, туалет, телефон, пластиковые окна, баня. Т. 8-937-664-45-07.

*1-комнатная квартира. Центр. Т. 8-937-580-20-79.

*срочно кап.гараж с дачей по ул. Шашина, собственность, торг. Т. 8-927-871-55-07.

*3-комнатная квартира, гараж, баня, огород. Т.: 8-927-434-34-43, 8-937-616-01-70.

*2-комнатная квартира в центре, индивидуальное отопление, 1 этаж, ремонт, 950000 руб. Т. 8-927-243-83-30.

*2-комнатная неизолированная квартира, 48,5 кв.м, 1 этаж, индивидуальное отопление, центр. Т. 8-927-447-52-08.

*дом с участком, с. Ст.Максимкино, Самарская обл., недорого. Т. 8-965-335-45-37.

*для тех, кто срочно нуждается в жилье! Т. 8-910-081-19-57.

*1-комнатная квартира, ул. Советская, 189. Т. 8-927-405-34-83.

*дом. Т. 8-927-462-17-01.

*дом, ул. Кирова, 7. Т. 8-937-286-22-39.

*дом, ул. Маяковского, 80 кв.м, участок 8 соток, гараж, баня, хоз.постройки, 1650 тыс. руб., торг. Т. 8-927-673-45-31.

*дом. Т. 2-04-04.

*2-комнатные квартиры, ул. Сайдашева, ул. Заводская; дом, ул. Михеева; дом, д. Вишневая Поляна. Т. 8-937-77-40-132.

*3-комнатная квартира, ул. Дружбы, 69. Т. 8-9274-222-456.

*жилой дом (ул. Декабристов, 47) или обменивается. Т. 8-917-929-86-81.

*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек, в хорошем состоянии. Т. 8-937-283-18-83.

***1-комнатная квартира**, ул. Гиматдинова, 90 (ремонт, мебель, 790 тыс.руб.), дом, ул. Фахрутдинова (2950 тыс.руб.), **недострой**, ул. Куйбышева, 840 тыс.руб., **недострой,** ул. Дальняя, 950 тыс.руб. Т. 8-937-600-47-73, Алсу.

## АВТОТРАНСПОРТ

*«Лада Калина», пробег 4000. Т. 8-937-528-81-91.

*«Шевролет Лачетти», серебристый, седан, 2008 г/в. Т. 8-917-922-31-69.

*«МАЗ» (самосвал), 2014 г/в, 20 т. Т. 8-987-286-70-01.

*«ВАЗ-2107», 2004 г/в. Т. 8-927-402-16-92.

*«ВАЗ-2107», 2007 г/в. Т. 8-917-265-70-19.

*«ЗИЛ» (дизель), состояние хорошее; «Нива», пробег 16000, бензин-газ. Т. 8-917-872-37-21.

*трактор «МТЗ-320.4», 2014 г/в, кун, ковш, вилы, косилка, цена 570000 руб. Т. 8-917-159-86-99.

*«Дэу Матиз», 2012 г/в. Т. 8-937-600-49-37.

*«ВАЗ-2105», 2006 г/в. Т. 8-937-620-04-26.

*«Форд Фокус-2 рестайлинг», 2011 г/в, 1,6 мт, цвет черный, хэтчбек, полная комплектация. Т. 8-961-389-91-94.

*«Калина», универсал, 2011 г/в, 44000 пробег, черная, один хозяин, небитая. Т. 8-937-520-69-88.

*«ВАЗ-21074», 2009 г/в. Т. 8-927-481-30-38.

*«КамАЗ-55111», 15 т. Т. 8-927-406-80-03.

## ДРУГОЕ

*куры-молодки. Т. 8-927-483-06-10, 8-917-293-27-47.

*утки, гуси, молодки, бройлеры. Доставка. Т.: 8-937-286-57-23, 8-937-621-81-57.

*бычки (молодняк) от 2 до 5 месяцев. Т. 8-927-870-58-98.

*ПГС, бут, песок. Т.: 8-927-248-19-66, 8-917-248-21-66.

*песок, ПГС, бут, керамзит, щебень, цемент. Т. 8-927-247-94-76.

*новый телевизор, дешево. Т. 8-927-437-65-75.

*банные камни. Т. 8-927-416-24-11.

*сруб для бани, новый; дрова. Т. 8-927-413-05-92.

*Камышлинский инкубатор реализует подрощенных бройлеров. Т.: 8-937-620-80-30, 4-35-47 (Румия).

*куры-молодки, утята, муларды. Т.: 4-35-11, 8-927-422-92-58.


**ПИЛОМАТЕРИАЛЫ**

**Сосна обрезная 6500 р.**

**Необрезная осина 3500 р.**

**- Строим дома из бруса (150х200) от 500 тыс. руб. до 800 тыс. руб.**

**- Срубы для бани.**

**- Двери банные.**

**- Услуги строителя.**

**8-927-441-54-65, 8-937-292-82-15.**


*семена – костер, люцерна. Т. 8-927-470-39-02.

*дрова. Т. 8-927-414-61-34.

*ПГС, бут, песок. Т. 8-937-617-11-21.

*дрова. Т. 8-937-003-27-27.

*стельная корова, 3-й отел в декабре. Т.: 8-927-457-16-40, 3-31-13.

*мелкий картофель. Т. 8-917-223-93-70.

*КУН усиленный, б/у на трактора МТЗ-80, ЮМЗ. Т.: 8-917-258-07-47, 8-937-580-21-09.

*вагон (3х11), 50000 руб., торг. Т. 8-917-392-09-02.

*ПГС, бут, песок. Т. 8-917-936-04-05.

*ПГС, песок, буткамень. Т. 8-917-230-77-88.

*козье молоко. Т. 8-927-443-76-66.

*песок, ПГС от 3 тонн. Т. 8-927-244-84-71.

*тумбочка, телевизор, диван, соковарка. Т. 8-927-047-16-31.

*поросята, с. Тюрнясево. Т. 8-937-572-00-55.

*говядина (молодняк) частями. Т. 8-937-286-56-64.

*корова черной масти, первотелка. Т. 8-927-428-95-83.

*холодильник двухкамерный, б/у. Т. 8-927-462-13-51.

*компьютерный стол (2500), компьютер (8000). Т. 8-917-276-24-65.

*корова. Т. 8-927-437-34-32.

## РАЗНОЕ

*Йомшак жиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.

*Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.

*тамада. Т. 8-960-088-23-94.

*копаем, заливаем фундамент, копаем траншеи и канализации, чистим колодцы. Качественно, вручную. Т.: 8-937-589-51-73, 8-987-274-95-46.

*установка окон, дверей, откосов. Т.: 8-927-671-26-59, 8-987-189-59-02.

*услуги электрика. Т. 8-937-614-70-15.

*копаем, чистим колодцы. Т.: 8-986-711-25-32, 8-929-723-88-60.

*ремонт холодильников. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.

*ГрузоГАЗель, межгород. Т. 8-927-486-10-22.

*быстро, качественно плитка, мозаика, все виды отделочных работ. Т. 8-987-971-15-18 (Геннадий).

*услуги электрика. Т. 8-987-418-35-00.

*ежедневно Нурлат-Самара, автовокзал, глазные клиники. Т. 8-927-031-29-33.

*покрытие ванн акрилом. Т. 8-987-409-98-49.

*подключаем Интернет, телефон, Летай-ТВ. Т. 8-927-240-53-83.

*грузоперевозки, «ГАЗель», 3 м, город-межгород. Т. 8-927-423-91-66.

*услуги каменщика, выполняем бетонные работы. Т. 8-937-294-65-52.

*копаем, чистим колодцы. Т. 8-937-776-79-45.

* Обшивка домов, кровля и другие строительные работы. Т. 8-9274-222-633.

* Утерянный техпаспорт и водительское удостоверение на имя Айрата Вазировича Халиуллина прошу вернуть за вознаграждение. Т. 8-9274-222-633.

## ТРЕБУЕТСЯ

*ООО «СК Регион» мастер участка водонасосной установки, з/п от 25000 руб. Т. 2-03-08.

*в ТСЦ «Мастерстан» продавец. Т.: 8-929-722-03-51, 8-937-290-95-11.

*электромонтер, слесарь-ремонтник, водитель. Т. 2-05-74.

*в ЗАО «Нурлатский сахар» инженер АСУ, слесаря-ремонтники (ТЭЦ, автотранспортный цех), строгальщик, электромонтер 6 раз., монтажники оборудования предприятий пищевой промышленности 5 раз., начальник смен основного производства, инженеры-технологи. Обращаться в отдел кадров по тел. 2-57-75.

*уборщики (-цы) в г.Казань. Вахта. 15/15. З/п 13 000,00 руб. Общежитие. Т. 8-917-915-08-32.

*массажист. Т.: 2-43-03, 2-43-04.

*уборщик (-ца), оклад 8000. Т. 8-937-777-00-08.

*столяр-станочник, специалисты по деревообработке и отделки. Т. 8-939-733-23-36.

*«Центр занятости населения г.Нурлат» приглашает пенсионеров для обучения компьютерной грамотности. Желающие могут обратиться в Центр занятости по адресу: г.Нурлат, ул. Хамадеева, д. 19. При себе иметь паспорт и пенсионное удостоверение. Телефон для справок: 2-46-30.

*в ООО «Татбурнефть-ЛУТР» мотористы цементировочных агрегатов, СМН-20. Обращаться: г. Нурлат, ул. Советская, 130. Т.: 92-456, 92-230, 92-930, 92-617.

*в ЭПУ «Нурлатгаз» инженер-программист, слесарь по эксплуатации и ремонту газового оборудования, повар 4 разряда. Адрес: ул. Гиматдинова, 158, т. 2-14-03.

*продавец-консультант (двери). Оклад + %. Т. 8-927-430-93-93.

## КУПЛЮ

*ЧИТ ИЛ МАШИНАЛАРЫ. КЫЙММӘТКӘ. Т. 8-927-456-00-07.

*КЫЙММӘТКӘ АВТО САТЫП АЛАМ. Т. 8-937-588-36-46.

*КРС, шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-412-29-99.

*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.

*баллоны кислородные и т.д. Т. 8-987-292-01-10.

*пух гусиный, утиный, старые подушки, перины. Т. 8-987-062-55-26.

*2-комнатную квартиру, ул. К. Маркса, д.4. Т. 8-927-675-63-10.

*передний ведущий мост для Т-40 и запчасти к нему. Т. 8-927-486-76-85.

*погреб для картошки. Т. 8-919-640-62-16.

*КРС, лошадь. Т. 8-927-481-30-38.


**ВНИМАНИЕ!!!**

**Только с 1 по 31 июля 2015 г.**

Компания "Оконные системы"




**Окно 1300х1400**

Подоконник 300 мм

Отлив 150мм

Монтаж с демонтажем

При заказе более 2-х окон:

**ПОДАРОК 1000р с окна***

| Rehau | KBE | Montblanc | Exprof |
|---|---|---|---|
| 7700руб | 7200руб | 6500руб | **6000**руб |

**Т. 8-927-742-66-67, 8-908-383-89-98**

*Подробности по указанным телефонам. Организатор: ООО "СВК". Реклама



ПЕЧАТНЫЙ САЛОН Г.НУРЛАТ ПРЕДЛАГАЕТ ВСЕ ВИДЫ

*НАРУЖНОЙ РЕКЛАМЫ:*

*- РЕКЛАМНЫЕ БАННЕРЫ;*

*- ВЫВЕСКИ НА УЧРЕЖДЕНИЯ;*

*- ИНФОРМАЦИОННЫЕ СТЕНДЫ;*

*- ПЛАНЫ ЭВАКУАЦИИ;*

*- ТАБЛИЧКИ ОФИСНЫЕ;*

*- АДРЕСНЫЕ ВЫВЕСКИ НА ЖИЛЫЕ ДОМА И МНОГОЕ ДРУГОЕ.*

Типография полного цикла. Изготовим печати, штампы, факсимиле.

**Ул. К.Маркса (за музыкальной школой). Т.: 2-04-12, 8-9274-87-27-87.**


## СДАЮТСЯ

*квартира посуточно, командировочным. Т. 8-927-456-05-69.

*дом, недорого. Есть все необходимое для проживания, с. Ст Максимкино. Т. 8-968-745-28-34.

*гараж с подъемником, инструментами, ул. Михеева, 14. Т 8-937-529-32-68.

*2-комнатная квартира на длительный срок, 1 этаж. Т.: 8-987-400-72-59, 8-929-725-56-15.

## СТОЛ НАХОДОК

*3 июля по ул. Советская была найдена связка ключей. Т. 2-39-97.

## ПОТЕРИ

*утерянное свидетельство о регистрации серии ВН №261085 выданное на ООО «Нурлат-Сэте», считать недействительным

*водительское удостоверение на имя Петра Антоновича Николаева прошу вернуть за вознаграждение. Т.: 3-48-59, 8-927-463-63-17.

## ОБМЕН

*деревянный дом (ж/д) на квартиру или продается. Т.: 8-927-467-42-69, 2-52-13.


**УСЛУГИ АВТОКРАНА, 25 т., вылет стрелы 21 м. 8-927-444-70-80.**



**ПОМОЩЬ В ОФОРМЛЕНИИ МАТЕРИНСКОГО КАПИТАЛА.**

8-927-483-05-33 (Алмаз).


**ВНИМАНИЕ, РОЗЫСК!**

Отделом МВД России по Нурлатскому району разыскивается Карюхин Владимир Анатольевич 26.11.1973 г.р., зарегистрированный по адресу: Нурлатский р-н, с.Тюрнясево, ул.Школьная д. 73, который 19 июня уехал на велосипеде проверять пчелиные ловушки и до настоящего времени его местонахождение неизвестно. Был одет: в синюю спецовку, красную бейсболку, передвигался на велосипеде.



Просим граждан, располагающих информацией о местонахождении разыскиваемого, сообщить по телефонам:

**8(84345)2-11-25, 2-46-42, 02.**

## Кайгы уртаклашабыз

Иске Чаллы авыл җирлеге Советы һәм башкарма комитеты, әтиләре, тормыш иптәше **Хәсән Минвәли улы ӘБДЕЛГАНИЕВНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, җирле Совет депутаты Рамил Хәсән улы Әбделганиевның һәм Әбделганиевлар гаиләсенең авыр хәсрәтләрен уртаклашалар, кайгылы көннәрендә сабырлык һәм түземлек телиләр.


Гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" АҖ www.tatmedia.ru www.nurlat-tat.ru Реклама хезмәте телефоны: 8 (84345) 2-36-12

"Дуслык" ("Дружба", "Туслах") газетасы Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

"Татмедиа" АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир С.Н. Хәйруллина

Тел.: 2-36-14

**Редакциянең адресы:** 423040, ТР, Нурлат шәһәре, К.Маркс ур., 19

**Электрон адрес:** e-mail: redak@list.ru

**Телефоннар:** 2-36-12 – җаваплы сәркатип, реклама бүлеге, факс

2-36-20 – рус бүлеге

2-36-13 - корреспондентлар

2-25-88 – бухгалтерия

**Нәшер итүче:** "ТАТМЕДИА" АҖ 420097, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2.

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы (Татарстан) идарәсе тарафыннан 2013 елның 16 маенда теркәлгән.

Теркәлү таныклыгы: ПИ № ТУ 16-01018

Бу сан "Татмедиа" АҖ филиалы "Идел – Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2.

Басуга тапшыру вакыты: график буенча – 14.30, фактта – 14.30

татмедиа

Тираж - 1700

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин.

Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булып чыгарга мөмкинлеге юк.

**Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**

Реклама белдерүләренең төгәллеге өчен реклама бирүче үзе җаваплы.

Газета **чәршәмбе** һәм **җомга** чыга.

Заказ №5957

Язылу индексы 16185

Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

12+


© Язмаларны күчереп бастыру редакциянең язмача рөхсәте белән генә мөмкин.

# КӨН АРТЫННАН КӨН

ЖИҢҮГӘ – 70 ЕЛ

## Ветераннарга игътибар икеләтә кадерле

**Чулпан авылыннан тыл хезмәтчәне, хезмәт ветераны Мөнир Әндәрҗанов өчен бу ел – икеләтә юбилей елы.**

Мартта аңа 85 яшь тулды, ә 9 майда барлык авылдашлары белән бергә ул Бөек Җиңүнең юбилей датасын каршылады.

Сугыш чорының гап-гади малаена тормыш сынауларны җитәрлек биргән. Яшьтәшләре кебек үк, аның да балачагы булмый диярлек, бу чорны сугыш сызып ата. Фашистлар илебезгә бәреп кергәндә, Мөниргә нибары 11 яшь була. Әмма ул чорда малайларга бик тиз олыгаерга туры килә. Мөнир дә өлкәннәр белән берәттән тылда җиңү көнен якынайту өчен тырыша.

– Сугыш башланды, ир-атларны фронтка алдылар, – дип искә ала ул. – Без, малайлар, хезмәт кошенә җир сөрдек, үгезләрдә урманнан агач ташыдык, миңа ат караучы булып эшләргә дә, лобогрейка белән уңыш җыярга да туры килде.

Шул рәвешле, армиягә кадәр 10 ел буе Мөнир Әндәрҗанов колхозда эшли, бер эштән дә карышмый, физик хезмәттән курыкмый. Армия чоры җиткәч, биш ел буе яхшы гына хезмәт итеп кайта. Туган ягына кайткач, леспромхозга эшкә урнаша. Авыр физик хезмәткә күнеккән егет биредә иң катлаулы участокта эшли – зур машиналарда агач ташый.

– Кышын машина кабынсын өчен, һәр көнне 100әр чиләк ягулык йөртергә туры килә иде, – дип сөйли Мөнир Әндәрҗанов. Мондый хатирәләрне авырлык белән искә ала ул, инде олпат яшьтәге ир-атның дулкынланудан күзләре яшьләнә. Ишле гаилә башлыгына көн саен иртәнге 3тә торырга туры килә. Башта йорттагы малларны карыйсы, аннан җәяүләп леспромхозга атлыйсы бар. Ә Әндәрҗановларның хуҗалыгы шактый зур була: абзар тулы мал-туар, кош-корт, ат та асрыйлар, умарта ояларын гына да 30ны тоталар. Яшь чакта күңел ачуларга вакыт юк иде безнең, ди. Хатыны белән көн-төн эшли алар, биш бала тәрбияләп үстерәләр. Мөнир аганың җәмәгате җирле хастаханәдә хезмәт куя, колхозчылар һәм аларның балаларын дәвалый. Тик менә шулкадәр хезмәт тә җитмәгән, күрәсең.

– Пенсиягә чыккач, нинди дә булса ихтыяҗ белән авыл советына килсәм, миңа: "Леспромхозга бар, алардан сора, син колхозчы түгел", – дип кенә боралар иде, – дип сөйли Мөнир ага һәм бер мисал да китерде. – Ничектер кышын трактор белән мәчеткә кадәр юлны чистартуларын сораган идем, миңа янә кире җавап бирделәр.

Шулай итеп, "колхозчы" булмагач, аны пай участоклары бүлгәндә дә нәүмиз калдыралар, ә 9 ел элек хатыны вафат булгач, аның өлешеннән дә мәхрүм итәләр. Гомере буе булмаса да, сугыш һәм аннан соңгы иң авыр чорда 10 ел туган колхозында тир түккән хезмәт ветеранының тормышында гаделсезлекләр күп очрый. Мондый мизгелләрдән Мөнир аганың күңеле тула, һәм ул бу зарларын шул көннәрдә үзе янына килгән район башлыгы Равил Кузюровка да житкерде. Равил Әфраимович ветеранны игътибар белән тыңлады. 86нчы яшь белән барган ветеран, минем янга район җитәкчесенең килеп, проблемаларымны тыңлаганы юк иде әле, бу – беренче очрак, ди. Ә проблемалар аның тормышында аз булмаган. Мөнир агага аларны бер ярдәмчесез һәм киңәшчесез хәл итеп килергә туры килгән. Шуңа да бүген олы яшьтәге ветеранның җирле түрәләргә үпкәсе дә бар. Гомеренең күпчелек өлешен леспромхозда эшләсә дә, ул авылныкы, үз кеше булып калган бит. 46 ел буе илебез хакына хезмәт куйган. Әмма ни генә булмасын, дәүләт аның сугыш чорындагы һәм аннан соңгы хезмәтенә лаеклы бәясен бирде. Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан Мөнир Әндәрҗановка район башлыгы республика Президенты Рөстәм Миннехановның котлау хатын һәм юбилей медален тапшырды. Ә җирле җитәкчелек тарафыннан игътибарга килгәндә, Равил Кузюров әйткәнчә, алар дәүләт түгел әле. Равил Әфраимович ел азагына кадәр Әндәрҗановларның пай җирләре мәсьәләсен хәл итәргә вәгъдә бирде, шунда ук район һәм ил яңалыклары белән дә уртаклашты.

– Хәзер Дәүләт Думасында Россиянең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан кертелгән сугыш чоры балаларына ярдәм итү турындагы проект карала, – диде район башлыгы ветеранга һәм закондагы пунктларның балачакларын сугыш сызып ташлаган Мөнир ага кебек ветераннарның да тормышын яхшыртачагына өметен белдерде.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**




МӨНИР ӘНДӘРҖАНОВ ИГЪТИБАР ТОЙДЫ

*Прокуратура хәбәрләре*

### ИНТЕРНЕТТА МӘГЪЛҮМАТ УРНАШТЫРМАГАННАР

Нурлат шәһәр прокуратурасы мәгариф учреждениеләрендә интернет челтәрендә мәгълүматлар урнаштыру турындагы законнарның үтәлешен тикшерде.

Тикшерү районның 33 белем бирү учреждениесенең рәсми сайтларында мәгълүмат "Россия Федерациясендә белем бирү турында" ФЗның 29 маддәсе 2нче өлешендә каралган күләмдә урнаштырылмавын күрсәтте. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, прокуратура Нурлат район судына әлеге белем бирү учреждениеләрен алда күрсәтелгән кимчелекләрне бетерергә мәҗбүр итү гаризасы белән чыкты һәм мәгариф бүлеге начальнигы адресына представление чыгарды. Прокуратураның гаризалары тулысынча канәгатьләндерелде, мәгариф учреждениеләренең җитешсезлекләре бетерелде, 30 вазифаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

### ЗАКОННЫ ҮТӘМӘГӘННӘР

Нурлат шәһәр прокуратурасы наркомания белән көрәш турындагы законның үтәлешен тикшерде. Тикшерү барышында ике авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан наркомания белән көрәшкә юнәлтелгән законнарның үтәлмәве ачыкланды. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, шәһәр прокуратурасы авыл җирлеге башкарма комитетлары җитәкчеләренә карата представление чыгарды, алар дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

### ӘЛӘМ ЭЛҮГӘ ҖИТДИ КАРАМАГАННАР

2014 елның 1 сентябреннән 2013 елның 21 декабрендәге "Россия Федерациясе әләме турында"гы Федераль конституцион законның 4нче һәм 6нчы маддәләренә үзгәрешләр кертү турындагы" закон үз көченә керде. Әлеге төзәтмәләр нигезендә, РФ Дәүләт әләме белем бирү учреждениеләре биналарында, аларның нинди милек формасында булуына карамастан, даими эленеп торырга яки аларның территорияләрендә урнаштырылган булырга тиеш.

Нурлат шәһәр прокуратурасы үткәргән тикшерү районның 54 белем бирү учреждениесендә алда күрсәтелгән закон таләпләренең үтәлмәвен күрсәтте. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, шәһәр прокуратурасы әлеге белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә карата представлениеләр чыгарды, алар дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

**Эдуард МИФТАХОВ, Нурлат шәһәр прокуроры урынбасары.**

ӨЧ КАДР




### МӘКТӘП ЯНЫНДА – ВЕЛОПАРКОВКА

Әле кайчан гына шәһәрдә уңайлы велопарковкалар эре сәүдә үзәкләре тирәсендә генә булса, хәзер ул Нурлатның 2нче мәктәбе янында да бар. Аны җиһазларга "Үз мәктәбеңә булыш!" акциясе кысаларында мәктәп чыгарылышлары ярдәм иткән.

– Мәктәп укучылары шәһәрнең төрле микрорайоннарында яшиләр. Шуңа да мәктәпкә велосипедларда килүче укучылар да байтак. Хәер, эшкә "тимер ат"ларда җилдереп килүче укытучылар да юк түгел. Махсус парковка ясавыбыз да велосипедчыларга уңайлык тудыру һәм бер үк вакытта сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау максатыннан, - ди мәктәп җитәкчелеге.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

ӨЧ КАДР




### МӘЙДАННЫ ВАЗОННАР БИЗИ

Шәһәрнең үзәк мәйданын төрле элементлар белән җиһазлау дәвам итә.

Күптән түгел биредә "Төзекләндерү биш" җәмгыяте яктырткычларга махсус вазоннарда чәчәкләр элеп чыкты һәм корыган 7 төп туя агачын яңага алыштырды. Җәмгыять директоры Ранис Рәхмәтуллин әйтүенчә, чәчәкләр өчен барлыгы 74 махсус вазон Мәскәүдән кайтартылган. Ә чәчәкләр – петунияләр үзебездә үстерелгәннәр. Үзәк мәйданны асылмалы вазоннар белән бизәү экологик, эстетик яктан отышлы һәм социаль функцияне дә башкара. Иң мөһиме, халык тудырылган матурлыкны саклый белсен иде, диләр җәмгыять хезмәткәрләре.

**Зилия ӘКСАНОВА**

ӨЧ КАДР




### ИҢ ЯХШЫ УЧАСТОККА - ГРАНТ

Районның 10нан артык мәктәп яны участогы "Иң яхшы мәктәп яны участогы" республика конкурсында катнашачак. Иң яхшы участокларга ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек һәм Мәгариф һәм фән министрлыклары грант бирәчәк. "Агымдагы елда районның барлык мәктәпләренә үзләрен яшелчә, җиләк-җимеш белән тәэмин итү бурычы куелды. Артып калган продукцияне кулай бәяләрдән балалар бакчаларына сату да булачак. Һәр участокта да бәрәңге, чөгендер, суган, тәмләткечләр һәм РАЙПО системасы аша кәбестә үсентеләре утыртылды, аларны педагоглар һәм укучылар карап тора. Хәзер конкурска иң яхшы участокларны сайлыйбыз. Биредә Киекле, Фома, Урта Камышлы, Тимерлек, Бикүле, Каравыл Тавы, Егоркино, Яңа Әлмәт, Кычытканлы мәктәпләре алдынгы", – ди мәгариф идарәсе начальнигы Линар Манәпов.

**Зилия ӘКСАНОВА**

# ТӨРЛЕ. РЕКЛАМА

ЯШЬЛӘР

## Аларны уртак һөнәр берләштерә



Автор фотосы

**Бу көннәрдә Нурлат район үзәк хастаханәсендә илебезнең медицина вузларыннан 25 студент практика уза. Үткән атнада хастаханәнең баш табибы Марат Йосыпов алар белән очрашу уздырды, районның сәламәтлек саклау системасы белән кыскача гына таныштырды.**

Бу яшьләрнең күбесе Чулпан хастаханәсенең легендар баш табибы Ксения Березина турында да беренче генә ишеткәндер, мөгаен. Баш табиб аның турында һәм авыл участок хастаханәсенә ни өчен Березина исеме бирү идеясе тууы хакында да сөйләде. Нурлат ЦРБсының тарихы белән кыскача гына таныштырды.

– Сезнең практикага кайтуыгыз иртәге эш урыныгыз белән танышу инде ул, – диде баш табиб яшьләргә мөрәҗәгать итеп. Марат Рафаэлович шунда ук вуз тәмамлап, Нурлат хастаханәсенә эшләргә кайтучы яшь белгечләргә нинди перспективалар ачылуы турында да сөйләде.

– Район халкы 60 меңнән артык кеше исәпләнә, димәк, тар белгечләрне без тулы ставка белән тәэмин итә алабыз, башка районнарда исә халык азрак, димәк, ставка да түбәнрәк, дигән сүз, – диде ул. Әмма яңалыклар бу гына түгел иде. Баш табиб әйтүенчә, торак белән дә проблема булырга тиеш түгел икән.

– Без район җитәкчелеге белән Дәүләт торак фондын районга кайтучы перспективалы табибларга һәм аларның гаиләләренә торак төзүгә җәлеп итү турында сөйләшүләр алып барабыз. Шулай ук хастаханәнең үз көче белән коммерцияле оешмалардан хезмәт торагы сатып алу мәсьәләсе дә карала, – диде Марат Йосыпов.

Бүгенге көндә район хастаханәсе участок педиатрларына, терапевтларга, шулай ук нефролог, кардиолог, невролог кебек тар белгечләргә мохтаҗ, соңрак эндокринолог та кирәк булачак. Ә бүгенге студент-медиклар арасында медицинаны күңел кушуы белән сайлаучылар аз түгел. Мисал өчен, 9нчы мәктәп чыгарылышы, бүген Казан дәүләт медицина университетының III курс студенты Камил Шәмсетдинов медицина вузын сайлау үземнең дә, поликлиникада табиб-лаборант булып эшләүче әниемнең дә теләге иде, ди. Укуы кыен булса да, бу һөнәрне сайлавыма үкенмим, ди Камил. Ә менә Фомадан Лиана Насыйбуллина КДМУны тәмамлаган ике апасы эзеннән киткән, бүген кыз үзе дә IV курста инде. Аның авылдашы һәм курсташы Гөлинә Абдрахманова: "Ни өчен медицинаны сайладың?" – дигән сорауга: "Кешеләргә ярдәм итәргә яратам", – дип җавап бирде.

Район хастаханәсенең төрле бүлекләрендә практика узучы Чабаксар, Ижау, Самарадагы медицина вузлары студентлары да өлкән коллегаларыннан тәҗрибә туплый. Әмма бу чор студентларга тәҗрибәле остазлар арасында эшләү белән генә дә истә калмаячак әле. Баш табиб әйтүенчә, практика азагында алар өчен табигать кочагында конкурс та оештырылачак. Тик монысы инде яшь коллегаларның белемен тикшерү түгел, ә аларны берләштерү өчен оештырылачак.

Сирень **СӘМӘРХАНОВА**

КЫСКАЧА

### ЮРТАКЛАР ДА, ЧАПТАРЛАР ДА ҖИЛДЕРӘ

Казан халыкара ипподромындагы унҗиденче чабыш көнендә дә Нурлат атлары призлы урыннар белән кайттылар.

Хуҗалары Григорий Шугаев һәм "Ягуар" спорт клубы булган Реплика-ГИШ туры биясе юртаклар арасында төркем призында 1600 метрлы дистанцияне беренче булып килде. Шул ук хуҗаларның Беркут туры айгыры Орлов юртаклары арасында 2400 метрлы дистанциягә уздырылган А.В.Соколов мемориалында икенче урын алды. Ф.С.Сибагатуллин исемендәге Нурлат ат заводының Алерт җирән биясе исә 3 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәк чиста токымлы чаптарлар арасында 1600 метрлы дистанциядә икенче килде.

Илназ **МӨБАРӘКШИН**

### ЯҢА КИТАП КАЙТТЫ

Нурлатның җирлекара китапханәсенә "Татарстан Республикасының тыл батырлары" тарихи басмасының 1нче томы кайтты, анда нурлатлылар турында мәгълүматлар да бар. "Хәтер китабы" сериясеннән булган басманың башка томнарында да якташларыбызның Җиңүгә керткән өлешләре мәңгеләштерелачак.

Маргарита **ЛИТТА**

**ГЛАВНОЕ В ОЧКАХ – ЭТО ЛИНЗЫ!**

*Отнеситесь к их выбору с особенным вниманием!*

*Салон «Доктор Оптика»*

*предлагает широкий ассортимент очковых линз.*

**г. Нурлат, ул. Советская, 120, т.: 2-17-88, 8-927-427-79-27, ул. Гиматдинова, 81, т.: 2-91-99, 8-937-610-69-30, ТЦ «Радуга» (2 этаж), т. 8-937-613-99-88, ТЦ «Шифа», ул. Кариева, 1Д.**

Лиц. №16-01-000675 от 13.12.2007г., выд. Фед.службой по надзору в сфере здравоохранения и соц.развития.

Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста.

Реклама

**Закупаем лом**

**черный**
**3А - 7000 руб./тн**
**5А - 6000 руб./тн**
**12А - 5500 руб./тн**
**цветной**
**медь - 255 руб./кг**
**алюминий - 55 руб./кг**
**АКБ - 35 руб./кг**

**Территория бывшего вещевого рынка.**

**Т.:8-917-932-01-50, 8-927-444-70-80.**

***-Профнастил***
***- Сайдинг***
***- Утеплитель***
***- Доборные элементы.***
***Доставка.***

*Выезд на замер - бесплатно. Кредит АО «ОТП Банк». Т.: 8-927-470-29-39, 8-987-409-27-06. Универсальный рынок, м-н «Инструмент-град».*

**«УДАЧА»**

**Продолжается набор групп для отдыха на Черном море выездом на поезде 5 и 15 августа. Т. 8-927-417-17-10.**

**ВПЕРВЫЕ, ТОЛЬКО 1 ДЕНЬ!!!**

***10 июля в ЗДАНИИ ТИПОГРАФИИ (ул.К.Маркса, 19) г.НУРЛАТ с 10-00 до 18-00***

**СОСТОИТСЯ ВЫСТАВКА-ПРОДАЖА ТРИКОТАЖА И ТЕКСТИЛЯ**

**от 20 РУБЛЕЙ**

***ЦЕНЫ НАПРЯМУЮ ОТ ПРОИЗВОДИТЕЛЯ!***

**ГРАНДИОЗНАЯ РАСПРОДАЖА!!!**

Реклама

**В КОНСУЛЬТАТИВНО-ДИАГНОСТИЧЕСКОМ ЦЕНТРЕ «САУЛЫК», Г. НУРЛАТ, УЛ. ЖЕМЧУЖНАЯ, 25, ВЕДУТ ПРИЕМ СПЕЦИАЛИСТЫ ИЗ Г. КАЗАНИ ПО СЛЕДУЮЩИМ НАПРАВЛЕНИЯМ:**

11 июля 2015 года
1. Взрослая, подростковая гинекология.
2. Кардиология, ревматология.
3. Неврология.
4. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследование сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное доплеровское картирование), исследования сосудов головного мозга, верхних и нижних конечностей.
5. Сосудистая хирургия, новый революционный метод при варикозной болезни вен, не требующий госпитализации и наркоза. Помощь при сосудистых звездочках.

12 июля 2015 года
1. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии. Ведение беременности.
2. Диетология.
3. Эндокринология.
4. Урология. Помощь при эректильной дисфункции, ЗППП, мужском бесплодии, хр.простатите, аденоме предстательной железы.
5. Врачи проведут исследования органов малого таза, плода на 1,2 и 3 триместрах.

18 июля 2015 года
1. Гастроэнтерология.
2. Взрослая, подростковая гинекология.
3. Педиатрия-кардиология.
4. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследование сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное доплеровское картирование).

КДЦ предоставляет услуги по ДМС через Нурлатский филиал СК

КДЦ предлагает услуги по ДМС через Нурлатский филиал СК «Чулпан».

Результаты обследования принимаются в БМСЭ.

Справки и предварительная запись по т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.

ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г. ОГРН 1021605358103.

**Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста**

Реклама

**ДОСТАВКА ПЕРЕГНОЙ, ЧЕРНОЗЕМ, ГРУНТ, ПЕСОК, ПГС, ДРОВА КОЛОТЫЕ, ЧУРБАКАМИ И ДЕФЕКАТ 8-937-280-94-84.**

**ПРОДАЮТСЯ**

**3-комнатные квартиры, 103 кв.м - 1200 тыс.руб., 128 кв.м - 1500 тыс.руб. в Тенеево, Кошкинский район, Самарская область (коммуникации, газ, вода, свет, канализация). Торг. Обмен. Т. 8-937-179-18-59.**

**ОО «Гарантия качества» предлагает ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА европейского качества по доступной цене заводского производства. Рассрочка без %, без участия банка. Т. 8-927-405-53-52.**

**ТРЕБУЮТСЯ ОХРАННИКИ С ЛИЦЕНЗИЕЙ И БЕЗ ЛИЦЕНЗИИ**

для работы на промышленных объектах в городах РФ.

*График работы - две недели через две.*

*Официальное трудоустройство. Бесплатное питание, проживание, доставка.*

*З/п 850-900 руб. сутки для охранников без лицензии, 1000-1150 руб. сутки - с лицензией.*

**Т. 8 937 986 76 81.**

*Государственное автономное профессиональное образовательное учреждение*

***«НУРЛАТСКИЙ АГРАРНЫЙ ТЕХНИКУМ»***

*объявляет прием на 2015-2016 г.*
*на базе 9 классов по профессиям:*
*Автомеханик*
*Повар, кондитер*
*по специальностям:*
*ТО и ремонт автомобильного транспорта*
*Механизация сельского хозяйства*
*Экономика и бухгалтерский учет (по отраслям: бухгалтер, кассир)*
*на базе коррекционной школы по профессиям:*
*Портной, Штукатур;*
*Филиал техникума в с. Черемшан осуществляет прием на на базе 9 классов по профессиям:*
*-Тракторист- машинист с/х производства*
*-Повар, кондитер по специальности:*
*-Механизация сельского хозяйства*
*на базе 11 классов по профессиям:*
*Электромонтер по ремонту и обслуживанию электрооборудования*
*Сварщик (электросварочные и газосварочные работы)*

***Прием документов ежедневно с 8:00 до 16:00 (кроме выходных) до 20 августа по адресам:***
***г. Нурлат, ул. Ленинградская, д.15, телефон: 8(84345) 2-47-95***
***с. Черемшан, ул. Полевая, д.1, телефон: 8(84345) 2-27-54 edu.tatar.ru***

*Лицензия № 6474, серия 16ЛО1 №0002347 от 13 мая 2015 г., выдана МОиН РТ.*

Реклама

**Военкомат г. Нурлат производит отбор кандидатов для поступления на в/службу по контракту в в/ч 21208 (г. Тольятти, Самарская обл.) на в/должности водителей кат. «Д» и «Е».**

**Продолжается набор для поступления на в/службу по контракту граждан возраста до 39 лет, отслуживших военную службу по призыву, годных к в/службе или годных с незначительными ограничениями, не имеющих судимость, также граждан, окончивших высшие учебные заведения, не отслуживших военную службу по призыву до 27 лет и не пребывающих в запасе.**

*Просим вас в кратчайшие сроки обратиться в военкомат г.Нурлат по адресу: ул. Нурлатская, 5 или по телефонам:*

**2-46-18, 2-46-17.**

**ООО «МИР КРОВЛИ»**

**реализует**

ПРОФНАСТИЛ С9, С20, С21, НС44, Н60, Н75 (оцинкованный и окрашенный), длина до 12 метров, металлочерепицу, металлосайдинг, металлоштакетник, профильную трубу, гладкий лист, доборные элементы. Утеплитель. Пароизоляция. Гидроизоляция. Поликарбонат. Теплицы. Доставка по городу бесплатно. Гарантия на всю продукцию.

**Т.: 8-927-826-53-32, 8-937-273-87-15, 8(84235) 2-75-35, 2-72-25.**

**E-mail: mir-krovli73@bk.ru**